РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.12.2018 Буа шәһәре № 412/ИК-п

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар тапканда, шулай ук файдалы казылмалар табу белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларын файдалану һәм саклау буенча муниципаль контрольне башкарганда тикшерүләр үткәрү административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законының 2016 елның 3 июлендәге 277-ФЗ номерлы редакциясендә, ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар тапканда, шулай ук файдалы казылмалар табу белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларын файдалану һәм саклау буенча муниципаль контрольне башкарганда тикшерүләр үткәрү административ регламентын (алга таба – Регламент) кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгару көненнән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Кәмәртдинов

Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 24 декабрендәге
412/ИК-п номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар тапканда, шулай ук файдалы казылмалар табу белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларын файдалану һәм саклау буенча муниципаль контрольне башкарганда тикшерүләр үткәрү административ регламенты

Муниципаль контроль башкарганда тикшерү үткәрүнең административ регламенты Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шул документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан соратыла һәм алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724 номерлы боерыгы; Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләнгән.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә аларның оештыру-хокукый формалары һәм милек формаларына карамастан юридик затлар, шәхси эшкуарлар, шулай ук физик затлар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар тапканда, шулай ук файдалы казылмалар табу белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларын файдалану һәм саклау буенча муниципаль контрольне башкарганда тикшерүләр үткәрү административ регламенты.

1.2. Кайсы ведомство карамагында һәм милек формаларына, шул исәптән федераль милек һәм Татарстан Республикасы милке булуына карамастан, муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан барлык җир асты муниципаль контрольлек объекты булып тора.

1.3. Муниципаль контроль Россия Федерациясе Җир кодексының төп нигезләмәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы һәм Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә һәм әлеге административ регламентта каралган тәртиптә үткәрелә.

1.4. Татарстан Республикасы «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контрольлек Татарстан Республикасы Буа муниципаль

районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы казна учреждениесе тарафыннан башкарыла.

1.5. Гомумтаралган файдалы казылмалар тапканда, шулай ук файдалы казылмалар табу белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларын файдалану һәм саклау буенча муниципаль контрольне башкарганда дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук гражданнар белән бәйләнешкә керә.

## 1. Цели и задачи муниципального контроля

2.1. Муниципаль контрольлекнең максаты булып Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә җир законнарын бозуларны ачыклау һәм юл куймау, шулай ук җир астын рациональ, нәтиҗәле файдалануны һәм килешү бурычлары үтәлешен контрольдә тоту тора.

2.2. Муниципаль контрольлекнең төп бурычлары булып юридик, вазыйфаи һәм физик затларның җир законнарын үтәвен, билгеләнгән таләпләрне (нормалар, кагыйдәләр, нормативлар) саклавын башкару тора.

2.3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы казна учреждениесе түбәндәгеләрне контрольдә тота:

1) җир астын файдалану буенча таләпләрне саклауны;

2) аренда килешүләрен үз вакытында төзүне һәм җир кишәрлекләренә дәүләт хокукын теркәүне;

3) юридик һәм физик затларның җир астын үзләштергәндә килешүдә билгеләнгән срокларны саклауны;

4) җир астын максатчан билгеләнеше һәм файдалануга рөхсәт төре буенча файдалануны;

5) җир астыннан файдалану хокукын өченче затка бирү тәртибен саклауны;

6) җиргә хокукны раслый торган билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документлар булмыйча рөхсәтсез файдаланырга ирек куймаучы тәртипне саклауны;

7) җирләрне тиешле вакытында кайтаруны;

8) җирләрнең торышы турында дөрес мәгълүматларны бирүне:

9) җирләрне максатчан билгеләнешендә файдалануга яраклы хәлгә китерү, яки аларны файдалы казылмалар (гомумтаралган файдалы казылмаларны да исәпкә алып) чыганакларын эшкәртү, төзелеш, агач хәзерләү, эзләнү һәм туфрак катламын бозуга китергән башка эшләр тәмамланганнан соң рекультивацияләү буенча бурычларны үз вакытында үтәүне. Шул исәптән, хуҗалык эчендәге һәм үз ихтыяҗлары өчен башкарылган эшләрне дә.

10) аренда түләвен үз вакытында һәм дөрес итеп түләүне;

11) җир кишәрлекләрендә законнарга яраклы рәвештә урнаштырылган межлау, геодезик һәм башка махсус билгеләрнең урнаштырылуын һәм сакланышын;

12) җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә тәртип бозуларны бетерү турындагы таләпләрнең үтәлешен һәм җир законнарының башкарылуын;

13) җирләрне файдалану мәсьәләләре буенча функция йөкләгән бурычлар нигезендә башкаларны.

2.4. Муниципаль җир контроле түбәндәге эзлеклелектә башкарыла:

1) тикшерүләрне планлаштыру;

2) тикшерүне үткәрүгә әзерлек;

3) тикшерүне үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

4) тикшерү үткәрү барышында ачыкланган тәртип бозу фактларына карата чаралар күрү;

5) җир законнарын бозуны бетерүне контольдә тоту.

## 3. Планлы тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Планлы тикшерү предметы булып юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик затның җир законнары нормаларын һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәве булып тора.

3.2. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан ешрак үткәрелми.

3.3. Планлы тикшерүләр Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе расланган еллык планнар нигезендә үткәрелә.

3.4. Еллык планлы тикшерүләр үткәрү планнарында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) эшчәнлекләре планлы тикшерелергә тиешле юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) атамалары, шәхси эшмәкәрләрнең фамилияләре, исемнәре, атасы исемнәре, эшчәнлеге планлы тикшерелергә тиешле юридик затларның урнашкан урыны яки шәхси эшмәкәрләрнең яшәү урыннары һәм аларның үз эшчәнлеген алып барган фактик урыны;

2) һәр планлы тикшерүне үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерү үткәрүне башлау датасы һәм үткәрү сроклары;

4) планлы тикшерүне башкаручы муниципаль контроль органы атамасы.

3.5. Планлы тикшерүләр үткәрүнең Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган еллык планы кызыксынган затлар игътибарына аны муниципаль берәмлекнең рәсми сайтына урнаштыру юлы белән җиткерелә.

3.6. Планлы тикшерүләр үткәрү елы алдындагы елның 1 сентябренә кадәр срокта, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ билгеләнгән тәртиптә планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы проектын «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы нигезләмәләрен исәпкә алып, шәһәр прокуратурасына юнәлдерә.

3.7. Планлы тикшерүләрне еллык планлы тикшерүләр үткәрү планына кертүгә нигезләр «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы белән билгеләнгән.

3.8. Муниципаль контрольне башкаручы орган тарафыннан планлы тикшерү уздыру турында аны үткәрә башлауга өч эш көненнән дә соңармыйча юридик затка һәм шәхси эшмәкәргә планлы тикшерүне уздыра башлау турында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары, муниципаль контроль органы карары яки боерыгы күчермәсен кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәреп һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә яисә башка үтемле ысул белән хәбәр ителә.

3.9. Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы урынга чыгып тикшерү үткәрүнең гомуми срогы елына кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

3.10. Урынга чыгып планлы тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары тарафыннан дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрү зарурлыгына бәйле булган искәрмәле очракларда, Урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү срогы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин кече предприятиеләр өчен иң күбе егерме эш көненнән дә артыграк чорга түгел, микропредприятиеләр өчен иң күбе – унбиш сәгатькә.

## 4. Планнан тыш тикшерү оештыру һәм үткәрү

4.1. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) юридик затның, шәхси эшмкәрнең мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозуның ачыкланган фактларын бетерү турындагы элегрәк бирелгән күрсәтмәләрне үтәү срогы узып китүе;

1.1) әгәр юридик затка, шәхси эшмәкәргә тиешле планнан тыш тикшерү үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) тәкъдим итү, рөхсәт бирү (килештерү) кагыйдәләрендә каралган булса, муниципаль контроль органына юридик зат яки шәхси эшмәкәрдән аерым төр эшчәнлекне алып бару хокукына яки башка юридик әһәмияткә ия гамәлләрне башкаруга рөхсәткә (килештерү) хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирү турында гариза керүе;

2) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән бәйләнешкә кермичә тикшерү буенча чараларның нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәләре буенча муниципаль контроль органы вазыйфаи затның дәлилләнгән күрсәтмәсе, муниципаль контроль органына гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан кергән мөрәҗәгать һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, гаммәви мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында мәгълүматларны карау яки беренчел тикшерү:

а) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә зарар килү, табигый һәм техноген холыктагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы тууы;

б) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян килүе, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә зарар килүе, табигый һәм техноген холыктагы гадәттән тыш хәлләр тууы;

в) кулланучылар хокукы бозылуы (кулланучылар хокукын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген башкаручы органга хокуклары бозылган граждан мөрәҗәгать иткән очракта, әгәр гариза бирүче үзенең бозылган хокукларын яклау (торгызу) өчен юридик затка, шәхси эшмәкәргә мөрәҗәгать иткән һәм андый мөрәҗәгать каралмаган яисә гариза бирүченең таләпләре канәгатьләндерелмәгән булса).

Мәҗбүри таләпләрне бозган зат турында төгәл мәгълүмат, мәҗбүри таләпләрне бозу турында җитәрлек мәгълүмат булмаса, муниципаль контроль органы тарафыннан кергән мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрелә ала. Алдан тикшерү барышында гариза һәм мөрәҗәгать җибәргән, мәгълүмат биргән затлардан өстәмә мәгълүматлар һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затларның, шәхси эшкуарларның дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы карамагында булган документларын карау үткәрелә, кирәк булса юридик зат, шәхси эшкуар белән бәйләнешкә кермичә һәм әлеге затларга мәгълүмат бирү һәм муниципаль контроль органы таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләми торган контроль чаралары үткәрелә. Алдан тикшерү кысаларында, кабул ителгән мәгълүматны юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән аңлатуларын сорарга мөмкин, әмма андый аңлатма һәм башка документлар бирү мәҗбүри түгел.

4.2. Муниципаль җир контроле органына мөрәҗәгать иткән затны ачыкларга мөмкинлек бирмәгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып хезмәт итә алмый.

4.3. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә планнан тыш урынга чыгып тикшерү әлеге административ регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгән нигез буенча, андый юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген башкарган урын буенча прокуратура органнары белән килештергәннән соң үткәрелә ала.

4.4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын планнан тыш тикшерү уздыру турында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе боерыкны имзаланган көнне, аны килештерү максатында муниципаль җир контроле органы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген

башкарган урын буенча прокуратура органына планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турында гаризаны тәкъдим итә яисә кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп яки электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон документ формасында юнәлдерә. Бу гаризага Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисенең планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турындагы боерыгы күчермәсе һәм аны үткәрергә нигез булган мәгълүматлар язылган документлар кушымта итеп куела.

4.5. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында муниципаль контроль органы юридик затка, шәхси эшмәкәргә, аны башларга егерме дүрт сәгатьтән дә соңармыйча теләсә нинди үтемле ысул белән хәбәр итә.

## 5. Тикшерүне оештыру тәртибе

5.1. Тикшерү Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе боерыгы нигезендә үткәрелә. Тикшерү боерыкта күрсәтелгән вазыйфаи зат яки вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелә ала.

5.2. Боерык тикшерүне үткәрүче Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ вазыйфаи заты имзасы белән, бер үк вакытта хезмәт таныклыгын күрсәтеп, юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки аның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка тапшырыла. Тикшерелергә тиешле затларның таләбе буенча тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлар үзләренең вәкаләтләрен раслау мәгълүматны тәкъдим итәргә тиеш.

5.3. Документар тикшерү һәм (яки) урынга чыгып тикшерү формасындагы планлы һәм планнан тыш тикшерүләр «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законының 11, 12 статьяларында каралган тәртиптә үткәрелә.

5.4. Тикшерүләрнең һәркайсының үткәрү срогы егерме эш көненнән артмаска тиеш.

## 6. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе

6.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ вазыйфаи заты ике нөсхәдә акт төзи (тикшерү актының үрнәк формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә).

6.2. Тикшерү актына мәйданны үлчәү схемалары, фототаблицалар, кирәк булганда җир кишәрлеген тикшерү акты, үткәрелгән экспертизаларның бәяләмәсе, мәҗбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозу өчен җаваплылык йөкләнгән юридик затның эшчеләре, шәхси эшмәкәрләр һәм физик затларның аңлатмалары, ачыкланган тәптип бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре кушымта итеп бирелә.

6.3. Тикшерү акты ул төгәлләнгәннән соң турыдан-туры ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аның берсе кушымталарның күчермәләре белән берлектә юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка тикшерү акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында язу алып тапшырыла. Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында язу бирүдән баш тарткан очракта, акт почта аша кулга тапшыру тамгасы белән заказлы хат итеп җибәрелә, ул муниципаль контрольлек органының эшендә саклана торган тикшерү актына өстәлә.

6.4. Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарурлыгы булганда, тикшерү акты контрольлек чараларын төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән

артмаган чорда төзелә һәм юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә язу алып тапшырыла яисә кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, ул муниципаль контрольлек органының эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә өстәлә.

6.5. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү өчен аны үткәрүне прокуратура органы белән килештерү таләп ителгән очракта, тикшерү актының күчермәсе тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул ителгән прокуратура органына тикшерү актын төзегән көннән соң биш эш көне эчендә җибәрелә.

## 7. Тикшерү барышында ачыкланган бозу фактларына карата муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары күрә торган чаралар

7.1. Тикшерүне үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат зарури таләпләрне яки муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерүне үткәргән муниципаль контрольлек органы вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләрне бурычлы:

1) ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча административ чаралар күрү өчен тикшерү материалларын Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Буа бүлегенә юнәлдерергә;

2) ачыкланган бозуларны бетерү артыннан контроль буенча чаралар күрергә;

3) җир законнарын бозуны бетерү турындагы күрсәтмәдә билгеләнгән срокта бозуны бетерү артыннан контрольне башкару.

## 8. Муниципаль контроль буенча чаралар үткәргәндә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирне кулланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлеге арендаторларының хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыклары

8.1. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирне кулланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлеге арендаторлары яисә аларның законлы вәкилләре муниципаль җир контроле буенча чаралар үткәрелгән түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәргәндә катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы сорауларга аңлатма бирергә;

2) тикшерү предметына кагылышлы һәм аны тәкъдим итү әлеге административ регламентта һәм башка норматив хокукый актларда каралган мәгълүматларны алырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзеңнең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуың, алар белән килешү яки килешмәвең, шулай ук муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының аерым гамәлләре турында күрсәтергә;

4) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының тикшерү үткәрү барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә.

8.2. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләре арендаторлары бурычлы:

1) муниципаль җир контроле буенча чаралар үткәрелгәндә үзләренең катнашуын яки үзләренең вәкаләтле вәкилләре катнашуын тәэмин итәргә;

2) җир кишәрлекләренә хокуклары турында документлар, проект-техник һәм җирләрне файдалану һәм саклау мәсьәләләрен көйләүче башка материалларны тәкъдим итәргә;

3) күрсәтелгән чараларны үтәгәндә муниципаль җир контроле буенча чаралар оештыруга һәм үткәрүгә ярдәм итәргә.

8.3. Тәртип бозган, тикшерү үткәрүгә дәлилсез киртә куйган, тикшерү үткәрүдән качкан һәм (яки) дәүләт контроле (күзәтчелек) органы, муниципаль контроль органының ачыкланган мәҗбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозуны бетерү турында күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлары яки юридик затларның

вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре, физик затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

9. Муниципаль контроль башкаручы вазыйфаи затларның хокуклары һәм бурычлары

9.1. Муниципаль җир контролен башкару буенча йөкләнгән бурычларны үтәү өчен муниципаль контроль башкаручы вазыйфаи зат үзенең компетенциясе кысаларында түбәндәгеләргә хокуклы:

Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге административ регламент белән билгеләнгән тәртиптә хезмәт таныклыгын күрсәтеп, контрольлек объектларына барырга һәм тикшерергә;

тикшерү нәтиҗәләре буенча җир законнары үтәлешен тикшерү актларын төзергә;

муниципаль җир контролен башкаруга киртә тудыручы гамәлләрне булдырмау яки юл куймау, шулай ук җирләрне файдалануны бозуда гаепле гражданнарның шәхесен ачыклауда ярдәм итү өчен эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә;

физик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар турында Бердәм дәүләт реестрыннан милек хәле, файланышы һәм сакланышы турында мәгълүматлар һәм материаллар, шул исәптән милеккә хокукны раслаучы, муниципаль берәмлек территориясендә контрольлек башкару өчен кирәк булган раслаучы документларны мөстәкыйль рәвештә соратырга һәм алырга;

ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар кабул итү турында мәсьәләләрне чишү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен прокуратура һәм эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә;

гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләләрне карау өчен гамәлдәге законнарны бозу турында материалларны контроль функцияләрен башкарган башкарма хакимият дәүләт органнарына җибәрергә;

Федераль салым хезмәте инспекциясенә сорату җибәрергә һәм муниципаль җир контролен башкару өчен кирәкле теләсә нинди мәгълүматларга алырга;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, Башкарма комитет структурасына кергән органнардан, барлык милек төрендәге оешмалардан үз функцияләрен башкару өчен кирәкле белешмәләр һәм башка документлар соратырга һәм алырга;

җир кишәрлекләренең хәле, файдаланышы турында мәгълүматларны һәм материалларны бушлай алырга, шул исәптән муниципаль җир контролен башкару өчен кирәкле җиргә хокукны раслаучы документларны.

9.2. Муниципаль җир контролен башкарган вазыйфаи зат тикшерү үткәргәндә бурычлы:

1) мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозуны кисәтү, ачыклау һәм туктату буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын һәм муниципаль хокукый актларны, физик затларның, юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

3) тикшерүне ТР Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең аны үткәрү турындагы боерыгы нигезендә аның билгеләнешенә яраклы рәвештә үткәрергә;

4) тикшерүне бары тик хезмәт бурычларын үтәгән вакытта гына үткәрергә, урынга чыгып тикшерүне хезмәт таныклыгын, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе карары күчермәсен һәм әлеге административ регламент белән каралган очракларда тикшерү үткәрүне килештерү турындагы документның күчермәләрен күрсәтеп кенә үткәрергә;

5) тикшерү үткәргәндә юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиленә катнашырга һәм тикшерү предметына кагылышлы сорауларга аңлатма бирергә каршы килмәскә;

6) тикшерү үткәргәндә катнашкан юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагылышлы мәгълүмат һәм документларны тәкъдим итәргә;

7) юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга.

9.3 Тикшерү үткәргәндә муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары хокуклы түгел:

1) мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең, әгәр әлеге таләпләр мунициналь контроль органы вәкаләтләренә карамаса, бу вазыйфаи затлар алар исеменнән гамәлләр кылса, үтәлешен тикшерергә;

1.1) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук мәҗбүри кулланышы Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә;

1.2) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

2) тикшерүне уздырганда юридик зат җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә аның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, планлы яисә урынга чыгып планнан тыш тикшерүне гамәлгә ашырырга, мондый тикшерү «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы 10 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктының «б» пунктчасында каралган нигез буенча уздырылган очрактан тыш, һәм шулай ук җир кишәрлеге милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир милекчеләренә һәм җир кишәрлеген арендага алучыларга тиешенчә белдергән очракларда җир законнары таләпләрен үтәүне тикшерергә;

3) документлар, мәгълүматлар, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын тапшыруны, әгәр алар тикшерү объектлары булып тормаса яисә тикшерү предметына карамаса, таләп итәргә, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен алырга;

4) продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу өчен күрсәтелгән үрнәкләрне, пробаларны алу турында беркетмәләрне билгеләнгән рәвешендә рәсмиләштермичә һәм илкүләм стандартларда билгеләнгән, үрнәкләрне, пробаларны алу кагыйдәләрендә һәм аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу методларында, техник регламентларда яки алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган бүтән норматив техник документларда һәм тикшеренүләрнең, сынауларның, үлчәмнәр алуларның кагыйдәләрендә һәм методларында билгеләнгән нормалардан артып китүче санда алырга;

5) тикшерү уздыру нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән сакланган башка сер булган, Россия Федерациясе законнарында каралган очракладан тыш, мәгълүматны таратырга;

6) тикшерү уздыру өчен билгеләнгән срокларны арттырырга;

7) юридик затларга алар хисабыннан контрольлек буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашырырга;

8) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган рөхсәт документларын да кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны тәкъдим итүләрен таләп итәргә;

9) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән тикшерүне үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар тәкъдим итүне таләп итәргә. Муниципаль контроль органы, тикшерү үткәрү турында әмер яки боерык кабул ителгәннән соң, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга хокуклы.

## 10. Тикшерү үткәргәндә вазыйфаи затларның җаваплыгы

10.1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ вазыйфаи затлары функцияләрне, хезмәт бурычларын тиешле башкармаган, тикшерү үткәргәндә законсыз гамәлләр кылган (гамәлләр кылмау) очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тота.

10.2. Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында, андый чараларны кабул иткән көннән ун көн эчендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ язмача рәвештә законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка хәбәр итәргә тиеш.

## 11. Вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү

11.1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ яисә аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү турындагы гариза Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә каралырга тиеш.

## 12. Муниципаль җир контролен башкаручы вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

12.1. Гариза бирүчеләр вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

12.2. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен гариза бирүчедән вазыйфаи зат карарына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдергән мөрәҗәгать керүе нигез булып тора.

12.3. Шикаять бирү тәртипләренә таләпләр:

шикаять язмача рәвештә казгазьдә, электрон формада районның Башкарма комитетына бирелә яки шәхси кабул итү барышында телдән әйтелә;

Башкарма комитет кабул иткән карарларга шикаять районның Башкарма комитеты җитәкчесенә (алга таба – мэр) бирелә;

Палата җитәкчесе карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять район Башкарма комитеты җитәкчесенә, район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына бирелә;

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять палата рәисенә бирелә;

Шикаятьне почта белән, күпфункцияле үзәк, Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен файдаланып, Буа шәһәре рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы яисә төбәк дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша җибәрергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итүдә белдерергә була.

12.4. Язмача шикаятьнең эчтәлегендә булырга тиеш:

муниципаль җир контролен башкарган органның атамасы;

карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән вазыйфаи затның вазыйфасы атамасы, фамилиясе, исеме, атасы исеме;

шикаять бирүченең фамилиясе, исеме, атасы исеме (атамасы), аның яшәү урыны (торган урыны), җавап җибәреләчәк почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы;

шикаять белдерелгән карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

гариза бирүче карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау) белән шулар нигезендә риза булмаган дәлилләр;

гариза бирүченең яки аның вәкиленең имзасы (мөһере – булган очракта) һәм дата.

Гариза бирүче шикаятьтә язылган дәлилләрне исбатлаучы документларны, яки аларның күчермәләрен тәкъдим итә ала. Андый очракта шикаятьтә аңа кушымта итеп куелган документлар исемлеге дә китерелә.

12.5. Гариза бирүче шикаятьне дәлилләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны алырга хокуклы.

12.6. Гариза бирүченең шикаяте кергән көнендә теркәлә һәм мэриядә аны теркәгән көннән 15 көч эчендә карала.

12.7. Телдән әйтелгән шикаятьнең эчтәлеге гариза бирүчене шәхси кабул итү карточкасына языла. Әгәр телдән шикаять белдергәндә әйтелгән фактлар һәм хәлләр күзгә күренеп торса һәм өстәмә тикшерүләр таләп итмәсә, шикаятькә җавап, гариза бирүченең ризалыгы белән, гариза бирүчене шәхси кабул итү барышында телдән бирелә ала. Башка очракларда шикаятьтә куелган сорауларның асылы буенча җавап язмача бирелә.

12.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча гариза бирүченең таләпләрен канәгатьләндерү яисә таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул ителә, бу хакта карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңармыйча гариза бирүчегә язмача рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап юнәлдерелә (гариза бирүче шикаятьтә шәхсән күрсәткән ысул белән, почта яки электрон почта аша).

12.9. Әгәр язмача формадагы шикаять тексты укылмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул тиешле компетенцияләре буенча дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка карау өчен юнәлдерелми, бу хакта шикаять теркәлгән көннән биш көн эчендә шикаять җибәргән гариза бирүчегә, әгәр аның фамилиясе (атамасы) һәм почта адресы яки электрон почта адресы укылырлык булса, җибәрелә.

Әгәр шикаять текстында әдәпсез яки мыскыллы сүзләр, вазыйфаи затның, аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм милкенә янаулар булса, вазыйфаи зат аңарда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча шикаятьне җавапсыз калдырырга һәм шикаять белдергән гариза бирүчегә хокукны чиктән тыш кулланырга ярамавы турында хәбәр итәргә хокуклы.

Әгәр шикаять текстында суд карарына шикаять белдерү турында сорау куелган булса, шикаять гариза бирүчегә аны теркәгән көннән җиде көн эчендә әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлату белән кайтарыла.

Әгәр шикаять текстындагы сораууга гариза бирүчегә элегрәк күп тапкырлар юнәлдерелгән шикаятьләр белән бәйле рәвештә асылы буенча язмача формада җаваплар бирелгән булса, һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр һәм хәлләр китерелмәсә, мэриянең шикаять юнәлдерелгән вазыйфаи заты, әгәр әлеге шикаять һәм элегрәк юнәлдерелгән шикаятьләр шул ук бер вазыйфаи затка юнәлдерелгән очракта, чираттагы шикаятьнең дәлилсез булуы һәм гариза бирүче белән әлеге мәсьәлә буенча язышуны туктату турында карар чыгарырга хокуклы. Бу карар шикаять юнәлдергән гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьтә гариза бирүченең фамилиясе (атамасы), җавап юнәлдерелергә тиешле почта адресы (торган адресы), электрон почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр шикаять текстында әзерләнүче, кылынучы яки кылынган законсыз гамәл, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүмат булса, шикаять аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына юнәлдерелергә тиеш.